СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.05.2025 № 58/1

На №__________ от______________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында

«Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Район Башкарма комитетына:
- «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасы чараларының үтәлешен тәэмин итәргә;
- РФ Эчке эшләр министрлыгының Тукай муниципаль районы буенча бүлеге белән берлектә, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз яшәү һәм законсыз хезмәт эшчәнлеген кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча эшне дәвам итәргә;
- этномәдәни һәм тел күптөрлелеген, балалар һәм яшьләрнең рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча эшне көчәйтергә.
3. Авыл җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:
- авыл җирлекләре территориясенә чит ил гражданнарының килүен системалы рәвештә анализларга.
4. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә конфессияара тынычлыкка һәм татулыкка кагылышлы мәсьәләләрне, шулай ук милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышланган чараларны яктыртырга.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров